КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 март г.Казань № 194

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында» 2023 ел, 15 сентябрь, 1143 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында» 2023 ел, 15 сентябрь, 1143 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2024 - 2026 елларга сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән акыл зәгыйфьлегенең төрле рәвешләре белән), эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалары буенча укытуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасындагы затларга түләүләр күләмнәре»;

2 пунктта «квалификацияле эшчеләрне, хезмәткәрләрне әзерләү,» сүзләрен «квалификацияле эшчеләрне, хезмәткәрләрне әзерләү программаларына, эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программаларына,» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга 2024 - 2026 елларга сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән акыл зәгыйфьлегенең төрле рәвешләре белән), эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалары буенча укытуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасындагы затларга түләүләр күләмнәрен өстәргә (карарга теркәлгән).

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 15 сентябрь, 1143 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 28 март, 194 нче
карары редакциясендә)

2024 - 2026 елларга сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән акыл зәгыйфьлегенең төрле рәвешләре белән), эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалары буенча укытуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасындагы затларга түләүләр күләмнәре

| Т/с | Социаль ярдәм төрләре буенча түләүләр исеме | Ел | Эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалар буенча белем алучыларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләме, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затларга уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга еллык пособие | 2024 | 3 339 |
| | | 2025 | 3 473 |
| | | 2026 | 3 612 |
| 2. | Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затларга айлык пособие (тиешле елның 1 сентябренә кадәр чорда түләнә торган) | 2024 | 1 110 |
| | | 2025 | 1 155 |
| | | 2026 | 1 202 |
| 3. | Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затларга айлык пособие (тиешле елның 1 сентябреннән кадәр чорда түләнә торган) | 2024 | 1 155 |
| | | 2025 | 1 202 |
| | | 2026 | 1 251 |

___